ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш
ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2025 елның 03 октябре 1871/ПИК

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022елның 28 июлендәге 1986 номерлы карары белән расланган торгларда милек буларак җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 октябрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы «Бердәм дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

**1.** «Җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 июлендәге 1986 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының торгларда милек буларак җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1. 3.5.4 нче пункт. яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы бер эш көнен тәшкил итә.»;

1.2. 3.6.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.5. Регламентның 3.6.2-3.6.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.6.2 - 3.6.4 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында

пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламент пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы 15 эш көне, җир кишәрлеге биреләчәк дигән хәбәр басылып чыккан очракта - 49 эш көне тәшкил итә.».

**2.** Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**